ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

19 май 2020 ел | № 2316

Муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында балаларны карау һәм тәрбияләү өчен ата-ана түләвенең бер өлешенә өстәмә компенсация бирү срогын озайту турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль ярдәмнең аерым чараларын бирү срогын озайту турында» 2020 елның 1 апрелендәге 241 номерлы карарының 2 пункты, шәһәр Уставының 41 статьясы нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Җан башына уртача кереме 20,0 мең сумга кадәр булган гаиләләргә муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында балаларны карау һәм тәрбияләү өчен, Башкарма комитетның 2013 елның 27 сентябрендәге 5863 номерлы карары белән билгеләнгән һәм аны түләү срогы 2020 елның 30 сентябренә кадәр чыга торган ата-ана түләвенең бер өлешенә өстәмә компенсация бирү срогын, гражданнар тарафыннан аларны алу өчен гаризаны кабат тапшырмыйча, 2020 елның 01 октябренә кадәр озайтырга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы И.А. Сәгыйдуллинага, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ

Ф.Ш. Салахов